**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕТИМЕРЛЕКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422670,Рыбно-Слободский район, ул. Советская, дом 4а**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ТЕГЕРМӘНЛЕК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**Совет урамы, 4А йорт, Югары Тегермәнлек авылы, Балык Бистәсе районы, ТР,422670**

**Тел.: (84361) 28001, факс: (84361) 28001, e-mail:Rs.Ntim@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 14 октябре Югары Тегермэнлек авылы №29

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермэнлек авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы “Үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында” 5номерлы карары белән расланган васыятьнамәләр һәм ышанычнамәләрне таныклау буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү Административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 26 июлендәге “Россия Федерациясе нотариат турында законнар Нигезенә һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 16.1 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында” 226-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы “Үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында” 5 номерлы карары белән расланган васыятьнамәләр һәм ышанычнамәләрне таныклау буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарның 1.5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

“1.5.Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәләрне таныклау буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламенты (Кушымта №5).”;

1.2) 5 номерлы кушымтада:

а) исемне яңа редакциядә бәян итәргә:

"Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәләрне таныклау буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламенты";

б) 1.1, 3.3.1. пунктларында "васыятьнамәләрне таныклау буенча һәм" сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 1.4 пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга;

г) 2.1 пунктынтүбәндәгередакциядәбәянитәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.1.Үзидарәлек хезмәтенеңисеме | Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәне таныклау | "Россия Федерациясенең нотариат турында законнар Нигезе" (РФ ЮС тарафыннанрасланган 11.02.1993 №4462-1) |

д) 2.3 һәм 2.4 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.3.Үзидарәлек хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен тасвирлау | Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәне таныклау буенча нотариаль гамәлләр кылу. Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәне таныклау буенча нотариаль гамәлләр кылуны кире кагу. | |
| 2.4.Үзидарәлек хезмәте күрсәтүсрогы | Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәләрне таныклау мөрәҗәгать иткән мизгелдән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла | |

е) 3.4.1. пунктының тугызынчы абзацында "васыятьнамәләрне нотариаль таныклау һәм" сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Югары Тегермэнлек авылы, Совет урамы, 72А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсемуниципаль районы
Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге башлыгы А.Н.Дмитриев